**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Комыргуҗа авыл җирлеге Ябынчы торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

“15” ноябрь 2024 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Ябынчы торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Ябынчы авылы территориясендә 2025 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан,80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- Ремонт, коймалар кую, традицион күмелгән урыннарны төзекләндерү (Ябынчы авылындагы зират территориясен чистарту (үлән чабу)).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Ябынчы авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Комыргуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Ябынчы авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Гатауллин Ф.Т.

СОВЕТ КОМЫРГУЖИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КОМЫРГУЖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ИНН 1610000733